Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2022 елның 06 октябрендәге 33 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2023 елның 10 июлендәге 296-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында»гы 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2022 елның 06 октябрендәге 33 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы район Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 маддәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн – әлеге гариза Советка кергән көн.»;

1.2. 18 маддәнең 1 пунктының б пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлап куелган органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, ширкәтнең съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш күчемсез милек

хуҗалары) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен) алдан хәбәр итүеннән;».

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы башлыгы,
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин